| | |
|---|---|
| ГЛАВА АЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**5 ноябрь 2024ел.** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Әлмәт авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Әлмәт авылы гражданнары җыенын Әлмәт авылы мәдәният йорты бинасында 2024 елның 20 ноябренә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, ялгыз өлкән кешеләр, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан , көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Әлмәт авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2025 елда үзара салымны 350 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1) Әлмәт авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту;

2) Әлмәт торак пунктының Ленин ур., Тукай ур., Яшьләр ур., Л. Рәхмәтуллин ур. буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (материалларны сатып алу һәм транспортировкалау, эш өчен килешү буенча түләү) ;

3) Әлмәт торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;

4) Әлмәт торак пунктында торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); МТЗ 82.1 тракторына, триммерлар һәм генератор өчен ягулык-майлау материаллары, МТЗ 82.1тракторына, триммерларга запас частьләр сатып алу);
скамейкалар сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү);

ӘЙЕ ЮК?».

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.
4. Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Әлмәт авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
5. Әлеге карар ул игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

«Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Д.Ә.Газизов

.